

Карповлар гаиләсенә кече Ватан тормышында катнашулары очен зур рәхмәтләребезне шәхсән мин һәм клуб хезмәткәрләре белдерә, - ди әдгәмәдә Рузаевка районы Татар Пешлә клубы модире Наталья Анатольевна Чалдаева.      Рузаевка районын Татар Пешлә клубына Волгоград шәһәреннән кунаклар килгән. Диана Наиль кызы белән Артур Анатольевич Карповлар гаиләсе Татар Пешлә клубынын Яна ел концертында иганәчеләр-спонсорлар булганнар: балалар очен татлы бvләкләр әзерләгәннәр, олылар очен ташламалы талоннар бирелгән.

Кунаклар Пешлә авылы милли татар мәдәнияте музеенын «Татар йорты»на да сәяхәт кылганнар. Музей экспонатларын, милли баш киемнәрен һәм костюмнарын, конкvреш һәм бизәкле әйберләрне карап, зур тәэсир алганнар; тарихы бер эпоханы эченә алган Татар Пешлә авылы vткәне-бvгенгесе аларнын хәтерендә озак сакланачак, киләчәк буынга да тапшырылачак.